**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Поручик авыл җирлегенең Канаш торак пунктында**

**2022 елның 23 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Канаш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Поручик авыл җирлеге Канаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- спорт мәйданчыгы сатып алу һәм аны урнаштыруга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Поручик авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Поручик авыл җирлеге башлыгы ____________ П.В. Тимаськов